БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » апрель 2018 ел № 131

**Балтач муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында**

"Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында" 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә һәм социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты кара бирә:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары ( алга таба – аерым оешмалар) җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык хезмәт окладыннан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, айлык акчалата бүләкләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, еллык түләүле отпуск алганда бер тапкыр бирелә торган түләүдән, матди ярдәмнән, шулай ук закон нигезендә башка түләүләрдән тора. Белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына шулай ук һөнәрләрне берләштергән өчен, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үзләренең төп эше белән беррәттән вакытлыча эшләмәүче хезмәткәрләрнең вазыйфаларын да башкару өчен өстәмә түләүләр кертелә;

аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык тариф ставкасыннан, компенсация түләүләреннән, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә өстәмәдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, ел саен бирелә торган түләүле отпуск алганда бирелә торган матди ярдәмнән, матди ярдәмнән, машина йөртүчеләргә класс өчен айлык өстәмә түләүләрдән, һөнәрләрне берләштергән өчен, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үзләренең төп эше белән беррәттән вакытлыча

эшләмәүче хезмәткәрләрнең вазыйфаларын да башкару өчен өстәмә түләүләрдән, шулай ук закон нигезендә башка түләүләрдән тора;

аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме Балтач муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладына тигез күләмдә 11 163,0 сум тәшкил итә;

аерым учреждениеләр эшчеләренә айлык тариф ставкаларын һәм компенсация түләүләрен исәпләү Балтач муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган Балтач муниципаль районының бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә.

2. Расларга:

Балтач муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентларын 1 нче кушымта нигезендә;

Балтач муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмаларының структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентларын 2 нче кушымта нигезендә;

Балтач муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары эшчәнлегенә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче эшчеләр өчен түләү разрядлары диапазонын 3 нче кушымта нигезендә.

3. Аерым оешмалар җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә билгеләргә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә, процент |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

3) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

5) еллык түләүле отпуск алганда бер тапкыр бирелә торган түләү елына вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә.

Әгәр җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә календарь ел дәвамында ел саен түләнә торган отпуск бирелмәсә, бер тапкыр бирелә торган түләү аңа декабрьдә эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм түләнә, эштән азат ителгән очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә еллык түләүле отпуск алганда бер тапкыр бирелә торган түләү беренче эш елында календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә кадәр исәпләнә;

6) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә матди ярдәм.

4. Белгечләргә һәм хезмәткәрләргә һөнәрләрне берләштергән өчен, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча эшләми торган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын башкарган өчен өстәмә түләүне билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды кысаларында төп эш буенча вазыйфаи окладның 50 процентына кадәр күләмдә билгеләргә.

5. Аерым оешмалар эшчеләренәтүбәндәгеләрне билгеләргә:

1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә түләүне айлык тариф ставкасының 50 процентына кадәр күләмдә, хезмәт җиңел автомобильләре йөртүчеләренә нормалаштырылмаган эш көне өчен өстәмә түләүне исәпкә алмыйча;

2) эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

3) еллык түләүле отпуск алганда бирелә торган матди ярдәмне айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы күләмендә.

Әгәр эшчегә календарь ел дәвамында ел саен түләнә торган отпуск бирелмәсә, бер тапкыр бирелә торган түләү аңа декабрьдә эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм түләнә, эштән азат ителгән очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Эшчегә еллык түләүле отпуск алганда бер тапкыр бирелә торган түләү беренче эш елында календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә кадәр исәпләнә;

4) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә матди ярдәм.

5) хезмәт җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә класс өчен айлык өстәмә түләүне түбәндәге күләмнәрдә:

I класслы йөртүчеләргә - машина йөртүче сыйфатында эшләгән вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасының 25 проценты,

II класслы йөртүчеләргә - машина йөртүче сыйфатында эшләгән вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасының 10 проценты;

6) айлык өстәмәне:

һөнәрләрне берләштергән өчен, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча эшләми торган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын башкарган өчен - билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды кысаларында гамәлдәге законнар нигезендә төп эш буенча айлык тариф ставкасының 50 процентына кадәр күләмдә;

төнге вакытта эшләгән өчен (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) – сәгатьлек тариф ставкасының 35 проценты күләмендә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен - икеләтә көнлек тариф ставкасы күләмендә;

хезмәт җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә нормалаштырылмаган эш көне өчен - айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә.

6. Хезмәткәрләргә федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләр башкарырга.

7. Аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда, вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчалардан тыш, түләү өчен түбәндәге акчалар каралуын билгеләргә (бер елга исәпләгәндә 12 вазыйфаи окладтан чыгып):

1) тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның җиде проценты күләмендә;

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр - вазыйфаи окладларның бер проценты күләмендә;

4) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның ике проценты күләмендә;

5) еллык түләүле отпуск һәм матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр бирелә торган түләү вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә.

8. Аерым оешмалар эшчеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда, тариф ставкаларын түләү өчен җибәрелә торган акчалардан тыш (компенсация түләүләрен исәпкә алып) түләү өчен түбәндәге акчалар каралуын билгеләргә (бер елга исәпләгәндә):

1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә - бер айлык тариф ставкасы күләмендә;

2) машина йөртүчеләргә класс өчен, нормалаштырылмаган эш көне өчен айлык өстәмә - тугыз айлык тариф ставкасы күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр - өч айлык тариф ставкасы күләмендә;

4) еллык түләүле отпуск алганда бирелә торган матди ярдәм - айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы күләмендә.

9. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, шулай ук аерым оешмалар хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләр күләме тулы бер сумга кадәр арттыру ягына түгәрәкләнергә тиеш;

әлеге карар кабул ителгәч, аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең башка шартлары кулланылмый.

10. Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасына билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

11. Аерым оешмалар җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәртипкә китерергә:

хезмәткәрләр вазыйфалары атамасын 1 нче кушымта нигезендә;

аерым оешмалар хезмәткәрләренә өстәмәләр һәм башка түләүләр билгеләү турында элегрәк чыгарылган актларны әлеге карар нигезендә.

12. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

"2012 елның 1 октябреннән Балтач муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" 2012 елның 23 ноябрендәге 1587 номерлы карары;

"2017 елның 1 октябреннән Балтач муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" 2017 елның 4 августындагы 211 номерлы карары.

13. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

14. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы финанс - бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>
Балтач район башкарма комитеты<br>
җитәкчесе Р. И. Шакиров